ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2020 г.Лениногорск № 1352

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2009 елның 17 сентябрендәге №1318 карары белән расланган Авыл җирендә яшәүче гражданнарга, шул исәптән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2020 ел, № 268-ФЗ Федераль закон нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2009 елның 17 сентябрендәге №1318 карары белән расланган Авыл җирендә яшәүче гражданнарга, шул исәптән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

2.5 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорларда) һәм гражданинның хезмәт хакы турында документлар, шулай ук производствода яки һөнәри авыруда булган бәхетсезлек очрагын тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән документлар;».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм гражданнарны күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М. Галимова
5-44-72